ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2023 г. Заинск № 205

**«Адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 12 декабрендәге 2844 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль ярдәм күрсәтүнең адреслы формаларының нәтиҗәлелеген арттыру, гражданнарның матди ярдәм күрсәтү турындагы гаризаларын карау эшен оештыруны камилләштерү максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

«Адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында» 2014 елның 12 декабрендәге 2844 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган (17.11.2015 №1907, 17.10.2016 №2279, 24.11.2016 №2687, 01.02.2018 №157, 02.04.2018 № 509, 10.05.2018№ 739, 22.06.2018№ 1023, 14.02.2019 № 51, 20.03.2019№ 141, 17.06.2019№313, 09.08.2019 № 423, 16.03.2020№ 100, 21.10.2020 №466 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) гражданнарга адреслы матди ярдәм күрсәтү буенча Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

"Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәтне өлешчә мобилизация буенча яки контракт буенча үткән, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон, Запорожье өлкәләре һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашканда һәлак булган (үлгән) хәрбиләргә кабер өстенә һәйкәлләр әзерләү һәм урнаштыру белән бәйле чыгымнарны үлгән кешенең туганнары (ата-аналары, тормыш иптәше, балалары) яки күрсәтелгән чыгымнарны үз өстенә алган башка кешеләрнең мөрәҗәгате нигезендә каплау.»;

1.2. 3.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

"Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәтне өлешчә мобилизация буенча яки контракт буенча үткән, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон, Запорожье өлкәләре һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашканда һәлак булган (үлгән) хәрбиләрнең туганнары ( ата-аналары, тормыш иптәше, балалары) яки күрсәтелгән чыгымнарны үз өстенә алган башка кешеләргә кабер өстенә һәйкәлләр әзерләү һәм урнаштыру белән бәйле чыгымнар өчен түләүне 30 000 сум күләмендә билгеләргә.».

2. Зәй муниципаль районы бюджетыннан матди ярдәм күрсәтүгә гаризаларны караганда мохтаҗлыкны билгеләү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертергә, аны кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р. Н.Камаловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Юрист
7 10 27

Р.Н.Камалова
8(85558) 3-41-22